# Көмеш кыңгырау

Кече Кибәхуҗа төп мәктәбендә нәшер ителүче айлык газета

Сентябрь, 2014 №1


## 1 сентябрь – Белем бәйрәме



*Көмеш кыңгыраулар суза*
*Тәүге дәрес җырын.*
*Белем йортларына уза*
*Ашкынып яшь буын.*
*Чакыра, тагын чакыра*
*Кыңгырау классларга.*
*Бүгеннән – Белем көненнән*
*Уку елын башларга.*
*Балалар кайта мәктәпкә,*
*Хушлашып җәйләр белән,*
*Көзге чәчәкләр һәммәсен*
*Тәбрикли бәйрәм белән.*


Бу санда:

- Белем бәйрәме
- Мәктәбебез яңалыклары
- Борынгы Болгар шәһәре – ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас объекты
- Китап – күңел көзгесе
- “Оборона һәм хезмәткә әзер!”
- “Уңышка юл” программасы гамәлдә!

# Белем бәйрәме



Республикабыз мәктәпләрендә яңа уку елы башлануын белдереп, беренче кыңгырау чыңлады. Безнең яраткан мәктәбебездә дә Белем бәйрәменә багышланган тантана булып үтте. Бәйрәмгә кунакка пенсионер укытучылар, район администрациясеннән Гиниятуллин И.С., "Игенче" ширкәте җитәкчесе Р.Р.Яхин, әти- әниләр килгән иде. Бәйрәмне мәктәп директоры Н.Н.Әхмәтҗанова котлау сүзе белән ачып җибәрде, укучыларга үзенең изге теләкләрен җиткерде. Мәктәбебезнең укыту-тәрбия буенча директор урынбасары Ф.Г.Аскарова. аеруча зур уңышларга ирешкән укучыларны һәм педагогларны котлап, бүләкләр тапшырды.  Бәйрәм укучыларга да, укытучыларга да, килгән ата-аналарга да, кунакларга да бик ошады.

Бәйрәм бетү белән, 2-6 сыйныф укучылары өчен "Минем кечкенә Ватаным " темасына беренче дәресләр үткәрелде . Дәресләрдә презентацияләр кулланылды. 4 сыйныф укучылары Татарстан территориясендә яшәүче халыкларның үзара дус яшәүләре турында сөйләштеләр. Алар дәрес ахырында картоннан төрле милләт кешеләре рәсемнәрен ясадылар һәм барысын бергә беркеттеләр.  Аннан соң үзләренең кулларын рәсемгә төшереп, аннан Дуслык Агачы ясадылар. Укучылар: "Дуслык агач тамыры кебек нык булырга тиеш", - дип әйттеләр.






## Дәрес вакытында...

# Мәктәп яңалыклары

- 18 август көненнән фән укытучыларының август киңәшмәләре башланып китте. Киңәшмәләрдә районыбыз мәктәпләре мөгаллимнәре укыту системасындагы яңалыкларны өйрәнделәр, яңа ФГОС ка күчү шартларында инновацияләр турында фикер алыштылар, алдагы эшчәнлекне оештыру планнарын расладылар.
- 20 август көнне бер төркем укытучыларыбыз район администрациясе ярдәме белән Бөек Болгарга сәяхәт кылды. Алар Болгар тарихи - археологик комплексы ЮНЕСКО ның Дөнькүләм мирас объекты исемлегенә кертелү уңаеннан оештырылган тантанада катнаштылар. Тантанага ТР Дәүләт киңәшчесе М.Шәймиев һәм ЮНЕСКОның генераль директоры Ирина Бокова да килгән иде. Экскурсиядә катнашучылар яхшы тәэсирләр белән кайттылар һәм чараны оештыручыларга зур рәхмәтләрен белдерделәр.



- 26 август көнне Теләче муниципаль районы мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе булып үтте. Август киңәшмәсенең пленар утырышында безнең мәктәпнең директоры Н.Н.Ахметзянова,укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Ф.Г.Аскарова, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Н.Д.Мухамадиева, башлангыч сыйныф укытучыларының берләшмә җитәкчесе Г.З.Гарипова, физика - математика укытучыларының берләшмә җитәкчесе Г.А.Галимҗановалар катнашты. Мәгариф министрының урынбасары Сулима Лариса Олеговна мәктәбебезнең беренче категорияле математика укытучысы Галимҗанова Гөлнур Әхмәтзәкиевнага "Мәгариф өлкәсендәге казанышлары" билгесен тапшырды.



- Шул ук көнне мәгариф хезмәткәрләренең пленар утырышында "Иң яхшы мәктәп яны тәҗрибә участогы" дип исемләнгән район бәйгесенең нәтиҗәсе билгеле булды. Мәктәбебез коллективы бу бәйгедә III урынны яулады һәм истәлекле бүләккә ия булды.



- 1 нче сентябрь көнне мәктәптә Белем бәйрәменә багышланган тантана булып үтте. Бәйрәмдә пенсионер укытучылар, район администрациясеннән Гиниятуллин И.С., "Игенче" ширкәте җитәкчесе Р.Р.Яхин, әти-әниләр дә катнашты. Бәйрәмнән соң "Минем кечкенә Ватаным" исеме астында беренче дәресләр үтте.



- Шул ук  көнне "Безнең иң яхшы укытучы" ("Наш лучший учитель") грантына ия булган укытучылар билгеле булды. Быел грант алучы укытучылар арасында филиалыбыз- Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбе укытучысы Мостафина Кадрия Мәсгутовна да бар.
- 3 нче сентябрь көнне мәктәбебездә "Экстремизмга -юк!" айлыгы башланды. Айлык план нигезендә үткәрелә. Дежур укытучы Галимҗанова Г.Ә. Беслан вакыйгаларына багышлап мәктәп күләмендә "Беслан кабатланмасын!" исемле ачык чара үткәрде. Чара барышында күрсәтелгән видео Беслан вакыйгаларын тулысы белән күз алдына китерде. Мондый коточкыч вакыйгалар кабатланмасын иде.Терроризмга,экстремизмга безнең җәмгыятьтә урын булырга тиеш түгел!
- 2 нче сентябрьдән  мәктәбебездә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 18 нче августында чыккан 16 2889 нчы номерлы хаты нигезендә “Сәламәтлек сәгате” дәресләре үткәрелә башлады. Дәресләр ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтындагы материалларга нигезләнеп үткәрелә.
- Башлангыч сыйныфлар укытучысы Гарипова Г.З. "Мәгариф" журналы үткәргән "Авыл укытучысы -2014" Бөтенроссия конкурсында катнашты. Тәҗрибәле укытучы үзенең күпьеллык эш тәҗрибәсе белән уртаклашты һәм Сертификатка ия булды.
- 14 нче сентябрь көнне мәктәптә эшләүче барлык хезмәткәрләр Дәүләт Советына сайлауларда катнашты.
- В этом году исполняется 200 лет со дня рождения М.Ю. Лермонтова (15.10.1814 – 27.07.1841) «Лермонтов дал первый толчок тому движению, которое впоследствии благодаря Гоголю,  Достоевскому и Толстому сделало русскую литературу литературой исповеди, вознесло на высоту недосягаемую, сделало искусством подлинно религиозным. Но и еще в одном отношении литература русская глубоко перед ним обязана: он жизнью своей создал для нас великий образец художника» говорил В. Ходасевич . Мероприятия к 200 летию со дня рождения М.Ю. Лермонтова проводятся указом ПРЕЗИДЕНТА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ О ПРАЗДНОВАНИИ 200-ЛЕТИЯ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ М.Ю. ЛЕРМОНТОВА. В связи с этим учитель русского языка и литературы И.М.Арсланова провела утренник, посвященный к знаменательной дате- 200 летию со дня рождения великого русского поэта М.Ю.Лермонтова.

# Борынгы Болгар шәһәре – ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас объекты

**2014елның 20 август көнендә Болгарда борынгы шәһәрне ЮНЕСКО исемлегенә кертүгә багышланган тантаналы чара узды**

Бәйрәм ЮНЕСКО генераль директоры Ирина Бокова һәм ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашында үтте.

Бәйрәмнең мәртәбәле кунаклары арасында Россиянең ЮНЕСКО каршындагы даими вәкиле Элеонора Митрофанова, ТР Президенты ярдәмчесе һәм “Яңарыш” фонды башкаручы директоры Татьяна Ларионова, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, РФ Комиссиясенең ЮНЕСКО эшләре буенча җаваплы секретаре Григорий Орджоникидзе, Россиянең Бөтендөнья мирасы илкүләм комитеты президенты Игорь Маковецкий бар иде. Шулай ук бу тантанада мәктәбебез укытучылары - без дә бар идек. Без рәсми тантанага кадәр, Болгарда тарихи һәйкәлләрне, музейларны карадык, аннары Истәлекле билге белән Җәмигъ мәчете арасындагы мәйданчыкка юнәлдек. Анда төп сәхнә һәм тамашачылар өчен зур экран урнаштырылган иде.

Ирина Бокова белән Минтимер Шаймиев тамашачылар алкышлары астында үз урыннарына уздылар. Тантаналы чара Болгар тарихына багышланган театральләштерелгән тамашадан башланды. Аннары төп сәхнәгә Ирина Бокова, Минтимер Шәймиев һәм республиканың Спас районы башлыгы Камил Нугаев чакырылды.

“Бүген бездә - зур бәйрәм. Безнең халыкның хыялы чынга ашты: Болгар тарихи-архитектура комплексы агымдагы елның июнендә ЮНЕСКО исемлегенә кертелде. Бу - безнең тарих. Мин сезне чын күңелемнән Татарстан Президенты һәм республиканың дәүләт органнары исеменнән котлыйм”, - дип мөрәҗәгать итте бирегә җыелучыларга М.Шәймиев. Ул шулай ук Ирина Боковага сертификат тапшыру өчен республикага шәхсән килүенә рәхмәт белдерде. Бу аның Татарстанга һәм аның күп милләтле халкына хөрмәтен күрсәтә.

Минтимер Шәймиев Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән Болгар тыюлыгы директорына, борынгы шәһәр туристларын һәм кунакларын йөртү өчен, 7 яңа электрокар һәм 5 автобус ачкычларын тапшырды. Тантаналы чара бәйрәм концерты белән дәвам итте.

Без тантанадан кайтышлый Ак мәчеттә дә булдык. Ул искиткеч гүзәл иде!

## Бөек Болгарга сәяхәттән күренешләр














# Китап- күңел көзгесе



24 сентябрь көнне китапханәче Нигъмәтҗанова Х.Н. мәктәп күләмендә "Китап- күңел көзгесе" исемле ачык чара үткәрде.Чарада укучылар китаплар тарихы , борынгы китаплар белән таныштылар, китап турында шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар, электрон китаплар белән таныштылар, "Таткнигафонд" аша китап уку мөмкинлекләрен күрделәр. Чарадан һәр бала китап уку теләге белән таралды.

# "Оборона һәм хезмәткә әзер!"(ГТО)

На старт!



Внимание!



Марш!

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының №3907/14 номерлы боерыгы нигезендә "Оборона һәм хезмәткә әзер!" (ГТО) дип исемләнгән Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын этаплап гамәлгә ашыру максатыннан, мәктәбебездә ГТО нормаларын тапшыруга әзерлек эшләре башланды. Спорт чараларын үткәрү графигы төзелде һәм һәр укучы бу чарада актив катнаша. Алар үзләренең ГТО нормаларын үти алулары белән кызыксыналар, нормаларын үтәргә тырышалар. Аеруча IV сыйныф укучысы Закиров Данияр ГТО нормаларын үтәүгә тулысы белән әзер.



Данияр, молодец!

# "Уңышка юл" программасы гамәлдә!

22-23 сентябрь көннәрендә мәктәбебезнең бер төркем укытучылары: Г.М. Закирова, И.Р. Шәяхмәтова, Г.З. Гарипова һәм мәктәпнең тәрбия буенча директор урынбасары Н.Д. Мөхәмәдиевалар Җөри урта мәктәбендә класс җитәкчеләре өчен оештырылган укуларда катнаштылар. Педагогик уку “Уңышка юл” программасының нигезләрен өйрәнүгә багышланды. Укуның беренче көннәрендә программаның  авторы, психологик фәннәр кандидаты И.Г.Вахрушина класс җитәкчеләренә теоретик белем бирде, уңышлы бала тәрбиялүнең асылына төшендерде. Икенче көнне практик өлешен практик –укытучы, тренер Николай Константинович алып барды. Практик өлешендә класс җитәкчеләре бала тәрбияләүдә ата-аналар белән эшләүнең иң кулай алымнары белән таныштылар, тәҗрибә тупладылар. Педагогик-психологик укулар класс җитәкчеләре өчен файдалы һәм эшлекле рәвештә үтте.





## "Уңышка юл" темасы астында әти- әниләр җыелышы




26 сентябрь көнне  мәктәптә "Уңышка юл" темасы астында әти- әниләр җыелышы булып үтте. Җыелышта район мәгариф бүлеге педагог-психологы Зиннатова Г.Р., полициянең участково - уполномоченные Газизов Р.И. катнашты.Җыелыш барышында мәктәп директоры Н.Н.Әхмәтҗанова укучыларның сәламәтлеге, мәктәптә укучыларны туклындыруның оештырылуы, ГТО нормативлары тапшыру, укучылар өчен оештырылган түгәрәкләр, Зиннатова Г.Р. әти- әниләр һәм балалар  арасында мөнәсәбәт,"Уңышка юл" программасы, Газизов Р.И. җинаятьләрне булдырмау, булган җинаятьләрне ачу  турында чыгыш ясадылар.

# Туган көннәрегез котлы булсын!

**Кече Кибәхуҗа төп мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы Асманова Тәслимә Миңнур кызын һәм Кече Кибәхуҗа төп мәктәбенең V сыйныф укучысы Гилязиева Радмилланы туган көннәре белән котлыйбыз! Сезгә нык сәламәтлек, озын гомер, ак бәхетләр, күп шатлыклар телибез.**



**Гомерегез хәзинәсенә,**
**Өстәлдә тагын бер ел.**
**Моңаймагыз еллар үтә дип,**
**Елмаегыз сез, бәхетле булыгыз.**
**Котлы булсын бәйрәмегез,**
**Тыныч булсын күңелегез.**
**Шатлык-сөенечләр белән,**
**Тулы булсын гомерегез.**
**Гамьле еллар, ямьле көннәр,**
**Телибез чын йөрәктән.**
**Һич кичекми чынга ашсын,**
**Безнең күркәм теләкләр.**



Малокибякозинская ООШ

**Газетаны гамәлгә куючы:**
**ТР Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе администрациясе**
**Баш мөхәррир:**
**II, IV сыйныф җитәкчесе**
**Г.З.Гарипова**
**Безнең адрес:**
**422080, Теләче районы, Кече Кибәхуҗа авылы, Кече урам, 10 нчы йорт.**
**Белешмәләр өчен телефон: 56 – 2 – 40**
**e-mail: mkibiakozi40@mail.ru**